РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЗНАКАЕВО АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин ур., 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.05.2023 ел № 17

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итүнең мәсьәләләре буенча кулланучыларның мөрәҗәгатьләрен тапшыру һәм карау турында

Россия Федерациясе Торак кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль Законына, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 27.07.2010 № 190-ФЗ Федераль Законына, «Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр», Азнакай шәһәре прокуратурасының 31.01.2023 елгы, №02-08-03-2023/Прдп33-23-2092004 «Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә федераль закон бозуларны бетерү турында» тәкъдимен үтәү йөзеннән Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итүнең мәсьәләләре буенча кулланучыларның мөрәҗәгатьләрен тапшыру һәм карау турында турындагы нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Җылылык бирү чорында кулланучыларның җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрен тәүлек буе кабул итүче орган - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының МКУ «Гражданлык сагы идарәсе» (Нигезләмә нигезендә) булуын билгеләргә.

2.1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының МКУ “Гражданлык яклау идарәсе” җитәкчесенә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының МКУ “Гражданлык яклау идарәсе” Уставына 2023 елның 1 маена кадәр үзгәрешләр кертергә;

- җылыту чоры дәвамында кулланучыларның җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итүнең мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрен тәүлек әйләнәсе кабул итүне гамәлгә ашыру бурычы турында вазифаи затларга - оператив дежурларга җиткерергә.

3. Җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итү мәсьәләләре буенча кулланучыларның мөрәҗәгатьләрен көн саен кабул итүче һәм караучы орган МУП «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү департаменты» (Нигезләмә нигезендә) булуын билгеләргә.

3.1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» җитәкчесенә:

- көндәлек, ягу чоры дәвамында җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итү мәсьәләләре буенча кулланучыларның мөрәҗәгатьләрен тәүлек буе кабул итү һәм карау башкара торган җаваплы вазыйфаи затны билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Җитәкче Э.А. Габдрахманов

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта
“_____”_______20_______№___

# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итү мәсьәләләре буенча нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итүнең мәсьәләләре буенча кулланучылар мөрәҗәгатьләрен тапшыру һәм карау тәртибе турындагы нигезләмә (алга таба - нигезләмә) халыкны җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итүнең мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр бирү процедурасын һәм механизмын, Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итүнең мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрне карау тәртибен билгели.

## 2. Язма мөрәҗәгатькә таләпләр

2.1. Кулланучылар мөрәҗәгатьләре язма рәвештә дә, телдән дә бирелергә мөмкин.

2.2. Юридик затларның мөрәҗәгатьләре җылылык белән тәэмин итү килешүе төзелгән очракта карауга кабул ителә, кулланучы - гражданнарның мөрәҗәгатьләре язма рәвештә төзелгән җылылык белән тәэмин итү килешүе булуга карамастан карауга кабул ителә.

2.3. Мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә мөрәҗәгать иткәндә тиешле, кирәк булган документлар исемлеге:

- гариза бирүченең шәхесен раслаучы документның күчермәсе (физик затлар өчен),
- җылылык белән тәэмин итү килешүнең күчермәсе (юридик затлар өчен),
-мөрәҗәгатьтә язылган фактларны раслаучы документларның күчермәсе. (булган очракта)

2.4. Кулланучылар мөрәҗәгатьләрен тапшыру тәртибе һәм кулланучыларга мәгълүмат бирү максатыннан кирәкле документлар исемлеге турында мәгълүмат Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

## 3. Җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрне кабул итү һәм карау тәртибе

3.1. Кулланучылар мөрәҗәгатьләре язма формада, шулай ук телдән дә, ә җылыту чоры вакытында - телдән дә түбәндәге ысуллар ярдәмендә бирелә ала:

- Азнакай муниципаль районының «Гражданнарны яклау идарәсе» диспетчерлык хезмәтенең тәүлек әйләнәсе эшли торган телефоны буенча (885592) 7-20-91;

- эш көннәрендә, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү Департаменты" телефоны буенча (885592) 7-35-65;

3.2. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү Департаменты»ның җаваплы вазыйфаи заты эш көннәрендә мөрәҗәгатьләрне 8.00 дән 12.00 кадәр, 13.00 тән 17.00 кадәр, бәйрәм алды көннәрендә 8.00 дән 12.00 кадәр, 13.00 тән 16.00 кадәр, җылыту чорында тәүлек әйләнәсе кабул итә.

Азнакай муниципаль районының МКУ «Гражданнарны яклау идарәсе» вазыйфаи заты ял һәм бәйрәм көннәрендә, җылыту чорында тәүлек әйләнәсендә мөрәҗәгатьләрне кабул итә.

3.3. МУП «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү Департаменты"ның җаваплы вазыйфаи затына килгән мөрәҗәгать (шикаять) теркәү журналында теркәлә һәм әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә карала.

Әгәрдә мөрәҗәгатьне МКУ «Азнакай муниципаль районының гражданнарны яклау идарәсе»нең вәкаләтле вазыйфаи заты алган икән, әлеге мөрәҗәгать (шикаять) теркәү журналында теркәлә һәм җаваплы вазыйфаи затка тапшырыла.

3.4. Мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң МУП «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү Департаменты»ның җаваплы вазыйфаи заты түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:

- мөрәҗәгатьнең характерын билгеләргә (кирәк булганда аны кулланучыдан ачыкларга);

- әлеге кулланучының җылылык белән тәэмин итүче һәм (яки) җылылык челтәре оешмасын билгеләргә;

- кулланучы тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген тикшерергә;

- мөрәҗәгать теркәлгәннән соң 2 эш көне дәвамында (җылыту чорында-3 сәгать дәвамында) аның күчермәсен җылылык белән тәэмин итүче һәм (яки) җылылык челтәре оешмасына җибәрергә һәм җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итүнең параметрларын, кире кагуның мөмкин булган техник сәбәпләре турында сорау җибәрергә, шул ук вакытта мөрәҗәгатьне җибәрү датасын, мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) теркәү журналында теркәргә тиеш.

3.5. Гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә, җылылык белән тәэмин итүче (җылылык челтәре) оешма, җибәргән сорауга 3 көн дәвамында (җылыту чорында 3 сәгать дәвамында) җавап бирергә тиеш. Әгәрдә МУП «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү Департаменты»ның җаваплы вазыйфаи заты күрсәтелгән вакытта сорауга җавап алмаган очракта, әлеге очракта ул бу хакта 3 сәгать дәвамында прокуратура органнарына хәбәр итәргә тиеш.

3.6 Җылылык белән тәэмин итүче (җылылык челтәре) оешмасыннан җавап алганнан соң, МУП «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү Департаменты»ның җаваплы вазыйфаи заты 3 көн эчендә (җылыту чорында 6 сәгать дәвамында) түбәндәгеләргә эшләргә тиеш:

-җылылык белән тәэмин итүче (җылылык челтәре) оешма белән берлектә җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итүнең параметрларын бозу сәбәпләрен билгеләргә;

- җылылык белән тәэмин итү буенча шул ук объектларны кулланып башкарыла торган, башка кулланучылардан шундый ук мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) бармы-юкмы икәнен билгеләргә;

- әлеге объектлар буенча үткән елда шундый мөрәҗәгатьләрнең булу-булмавын тикшерү;

- кирәк булганда кулланучылар мөрәҗәгатьләренең нигезлелеген тикшерү;

- кулланучылар мөрәҗәгатьләрендә язылган фактларны раслаганда, җылылык белән тәэмин итүче (җылылык челтәре) оешмасына әлеге чараларны үткәрү срокларын күрсәтеп, җылылык белән тәэмин итү параметрларының начарлану сәбәпләрен кичекмәстән бетерү турында күрсәтмә бирергә.

3.7. Кулланучының мөрәҗәгатенә җавап 5 эш көне дәвамында (җылыту чорында 24 сәгать дәвамында) тапшырылырга тиеш. Җибәрү датасы һәм вакыты мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) теркәү журналында билгеләнергә тиеш.

3.8. МУП «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү Департаменты»ның җаваплы вазыйфаи заты күрсәтмәнең үтәлешен җылылык белән тәэмин итүче (җылылык челтәре) оешма тарафыннан контрольдә тотарга тиеш.

3.9. Җылылык белән тәэмин итүче (җылылык челтәре) оешмасы МУП «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү Департаменты»ның вазыйфаи затның чыгарылган күрсәтмәсен судта шикаять итәргә хокуклы.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итүнең мәсьәләләре буенча кулланучылар мөрәҗәгатьләрен бирү һәм карау тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта

## Җылылык белән ышанычлы рәвештә тәэмин итү мәсьәләләре буенча кулланучыларның мөрәҗәгатьләрен (шикаятьләрен) теркәү журналы

| № п/п | Мөрәҗәгать итү датасы һәм вакыты | Кулланучының ф.и.о | Яшәү адресы | Мөрәҗәгатьнең характеры (асылы) | Кемгә һәм кайчан карау өчен тапшырылган | Җылылык белән тәэмин итү оешмасына мөрәҗәгать итү датасы һәм вакыты | Җылылык белән тәэмин итүче оешманың җавап бирү датасы һәм вакыты | Прокуратурага мөрәҗәгать итү датасы һәм вакыты | Күчмә тикшерү датасы һәм вакыты | Җылылык белән тәэмин итү оешмасына күрсәтмә җибәрү датасы һәм вакыты | Җылылык белән тәэмин итүче оешманың күрсәтмәне үтәү нәтиҗәләре | Кулланучыга җавап |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | |